КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 18 февраль г.Казань № 95

Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре һәм фәнни белгечлекләр буенча укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмен һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль берәмлекләренең җирле бюджетларының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре һәм фәнни белгечлекләр буенча укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмен килештерү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 59 статьясындагы 2 өлеше һәм «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясындагы 3 өлешенең 1 пунктындагы унберенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу кararга теркәлгән Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре һәм фәнни белгечлекләр буенча укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмен һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль берәмлекләренең

җирле бюджетларының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре һәм фәнни белгечлекләр буенча укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмен килештерү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 18 февраль, 95 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре һәм фәнни белгечлекләр буенча укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмен һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль берәмлекләренең җирле бюджетларының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре һәм фәнни белгечлекләр буенча укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмен килештерү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 59 статьясындагы 2 өлеше һәм «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясындагы 3 өлешенең 1 пунктындагы унберенче абзацы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре һәм фәнни белгечлекләр буенча укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмен һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль берәмлекләренең (алга таба – муниципаль берәмлекләр) җирле бюджетларының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән һөнәрләр, белгечлекләр, әзерләү юнәлешләре һәм фәнни белгечлекләр буенча укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмен (алга таба – укырга кабул итүнең контроль саннары), алар расланганчы һәм Татарстан Республикасы, тиешле муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан, тиешле мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашырган оешмалар арасында бүленгәнче, килештерү тәртибен билгели.

2. Урта һөнәри һәм югары белем бирүнең мәгариф программалары (алга таба – мәгариф программалары) буенча, шулай ук аспирантурада (адъюнктурада) фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча белем бирү өчен фәнни белгечлекләр төркемнәре һәм (яисә) фәнни белгечлекләр (алга таба – фәнни белгечлекләр) буенча гражданнарны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән укырга кабул итү максатларында республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йөкләмәсе буенча законнар нигезендә мәгариф программалары буенча, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән фәнни белгечлекләр буенча белем бирүне гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын гамәлгә куючылар ел саен, укырга кабул итүнең контроль саннары билгеләнә торган елга кадәрге 20 июленә кадәр, ачык конкурс нәтиҗәләре буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы

оешмалар арасында алга таба бүлү максатларында расларга планлаштырыла торган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән мәгариф программалары буенча белем бирү өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең эреләтелгән төркемнәре һәм (яисә) фәнни белгечлекләр буенча кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмнәре проектларын Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына килештерүгә кертә.

3. Гражданнарны муниципаль берәмлекләрнең җирле бюджетлары акчасы исәбеннән мәгариф программалары, шулай ук фәнни белгечлекләр буенча укырга кабул итү максатларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары ел саен, укырга кабул итүнең контроль саннары билгеләнә торган елга кадәрге елның 10 июленә кадәр, ачык конкурс нәтиҗәләре буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар арасында алга таба бүлү максатларында расларга планлаштырыла торган муниципаль берәмлекләрнең җирле бюджетларының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән мәгариф программалары буенча белем бирү өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре һәм (яисә) һөнәрләрнең, белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең эреләтелгән төркемнәре һәм (яисә) фәнни белгечлекләр буенча укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмнәре проектларын Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына килештерүгә кертә.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы әлеге Тәртипнең 2, 3 пунктларында күрсәтелгән укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмнәре проектлары кергән көннән алып 10 эш көне эчендә тапшырылган укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмнәре проектларын карап тикшерә һәм әлеге проектларны килештерү турында яисә килештерүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмнәре проектын килештерүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез була:

«Инженерлык эше, технология һәм техник фәннәр», «Авыл хуҗалыгы һәм авыл хуҗалыгы фәннәре» дигән урта һөнәри һәм югары белем бирү буенча һөнәрләрнең, белгечлекләрнең, әзерлек юнәлешләренең эреләтелгән төркемнәре буенча укырга кабул итүнең контроль саннарының проектлана торган гомуми күләмнәре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы икътисадының кадрлар әзерләүгә ихтыяҗын фаразлау, югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләү һәм кадрларны тизләтеп әзерләү өчен Татарстан Республикасының дәүләт заказын формалаштыру регламентын раслау турында» 2014 ел, 31 март, 208 нче карары нигезендә әлеге эретелгән төркемнәр буенча югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләү өчен формалаштырылган Татарстан Республикасының дәүләт заказы (алга таба – дәүләт заказы) күләмнәреннән 50 проценттан да артып китү;

«Математика һәм табигый фәннәр», «Сәламәтлек саклау һәм медицина фәннәре», «Җәмгыять турында фән», «Мәгариф һәм педагогика фәннәре», «Гуманитар фәннәр», «Сәнгать һәм мәдәният» дигән урта һөнәри һәм югары белем бирү

буенча һөнәрләрнең, белгечлекләрнең, әзерлек юнәлешләренең эреләштелгән төркемнәре буенча укырга кабул итүнең контроль саннарының проектлана торган гомуми күләмнәре әлеге эреләштелгән төркемнәр буенча дәүләт заказы күләмнәреннән 15 проценттан да артып китү.

5. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә аны әлеге Тәртипнең 2 һәм (яисә) 3 пунктларында күрсәтелгән укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмнәре проектларын килештерүгә керткән республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына җиткерә.

6. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан әлеге Тәртипнең 2 һәм (яисә) 3 пунктында күрсәтелгән укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмнәре проектларын килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, әлеге укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми проектларын керткән республика башкарма хакимият органы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы килештерүдән баш тарту кәгазен алган көннән алып өч эш көненнән артмаган срок эчендә укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмнәренең эшләп бетерелгән проектларын кабат килештерүгә җибәрә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы әлеге Тәртип нигезендә укырга кабул итүнең контроль саннарының гомуми күләмнәренең эшләп бетерелгән проектларын карап тикшерә.

_______________________________